РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
НАРМОНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НАРМОНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 55-0-43, факс 55-0-43

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**06 август, 2020 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын куллану сораулары буенча гражданнар җыены билгеләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законының 56, 25.1 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы “Нармонка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 23 маддәсе нигезендә **КАРАР БИРӘМ:**

1.2020 елның 19 августында 10 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлегенең Нармонка торак пунктында урнашкан “Нармонка урта гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясе бинасында гражданнарның үзара салым чараларын куллану сораулары буенча халык җыены үткәрергә.

2.Халык җыенында тәкъдим ителүче сорауны раслау:

“Сез, 2020 елга җыелган 150605 (йөз илле мең алты йөз биш) сум күләмендәге гражданнарның үзара салым акчаларын “Нармонка авылының суэтем каланчасы территориясен койма белән әйләндереп алу”дан “Нармонка авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү өчен вак таш сатып алу”га күчерергә ризамы?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Нармонка авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү йөкләнелә.

4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы”нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырып халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар басылган көненнән башлап үз көченә керә.

**Т.А. Хакимов**